ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О Торгово-промышленной палате Республики Татарстан

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
26 октября 2017 года

Статья 1. **Предмет регулирования настоящего Закона**

Настоящий Закон в соответствии с Законом Российской Федерации от 7 июля 1993 года № 5340-1 «О торгово-промышленных палатах в Российской Федерации» (далее – Закон Российской Федерации «О торгово-промышленных палатах в Российской Федерации») определяет статус Торгово-промышленной палаты Республики Татарстан (далее – Палата), а также регулирует отдельные правоотношения в сфере взаимодействия Палаты с органами государственной власти Республики Татарстан.

Статья 2. **Статус Палаты**

1. Палата является негосударственной некоммерческой организацией, созданной в организационно-правовой форме союза, объединяющей на добровольной основе российских юридических лиц, в том числе российских организаций, объединяющих юридических лиц и (или) индивидуальных предпринимателей, а также индивидуальных предпринимателей, зарегистрированных в порядке, установленном законодательством Российской Федерации.

2. Палата осуществляет свою деятельность в соответствии с Законом Российской Федерации «О торгово-промышленных палатах в Российской Федерации», другими федеральными законами и иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, настоящим Законом, другими законами Республики Татарстан и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан, со своим уставом.

3. Принципы и порядок образования, а также прекращения деятельности Палаты определяются Законом Российской Федерации «О торгово-промышленных палатах в Российской Федерации».

4. На территории Республики Татарстан может быть образована только одна торгово-промышленная палата республиканского уровня.

Статья 3. **Цели и задачи Палаты**

1. Палата создается в целях содействия развитию экономики Республики Татарстан и экономики Российской Федерации, формированию современной промышленной, финансовой и торговой инфраструктуры, созданию благоприятных условий для предпринимательской деятельности, урегулированию отношений предпринимателей с их социальными партнерами, всемерному развитию всех видов предпринимательства, торгово-экономических и научно-технических связей предпринимателей в Республике Татарстан с предпринимателями других субъектов Российской Федерации и зарубежных стран.

2. Палата выполняет следующие задачи:

1) оказывает помощь организациям и индивидуальным предпринимателям в Республике Татарстан, представляет и защищает их интересы по вопросам, связанным с осуществлением хозяйственной деятельности, в том числе за пределами Республики Татарстан и за границей;

2) содействует развитию всех видов предпринимательской деятельности с учетом экономических интересов Республики Татарстан и Российской Федерации, отраслей экономики, организаций и индивидуальных предпринимателей;

3) организует взаимодействие между субъектами предпринимательской деятельности в Республике Татарстан, их взаимодействие с органами государственной власти Республики Татарстан и органами местного самоуправления в Республике Татарстан (далее – органы местного самоуправления), а также с социальными партнерами;

4) содействует развитию системы образования и подготовки кадров для предпринимательской деятельности в Республике Татарстан, участвует в разработке и реализации государственных и межгосударственных программ в этой области;

5) участвует в разработке прогнозов социально-экономического развития Республики Татарстан, плана мероприятий по реализации стратегии социально-экономического развития Республики Татарстан, государственных и муниципальных программ в области развития предпринимательства;

6) содействует развитию инвестиционной деятельности, государственно-частного партнерства, муниципально-частного партнерства в Республике Татарстан;

7) оказывает предпринимателям, их объединениям, союзам, ассоциациям информационные услуги, содействует в организации инфраструктуры информационного обслуживания предпринимательства;

8) содействует развитию экспорта производимых на территории Республики Татарстан товаров и услуг, оказывает практическую помощь организациям и

индивидуальным предпринимателям в Республике Татарстан в проведении операций на внешнем рынке и освоении новых форм торгово-экономического и научно-технического сотрудничества;

9) принимает меры, в рамках предоставленных ей прав, к недопущению и пресечению недобросовестной конкуренции и неделового партнерства;

10) содействует урегулированию споров, возникающих между субъектами предпринимательской деятельности в Республике Татарстан;

11) обеспечивает предоставление услуг, необходимых для осуществления коммерческой деятельности иностранных фирм и организаций;

12) выполняет другие задачи с учетом положений Закона Российской Федерации «О торгово-промышленных палатах в Российской Федерации», международных договоров Российской Федерации, соглашений об осуществлении внешнеэкономических и межрегиональных связей Республики Татарстан.

Статья 4. **Взаимодействие Палаты с органами государственной власти Республики Татарстан**

1. Палата осуществляет взаимодействие с органами государственной власти Республики Татарстан, в том числе путем:

1) направления в органы государственной власти Республики Татарстан предложений по совершенствованию законов Республики Татарстан, иных нормативных правовых актов Республики Татарстан в сфере предпринимательства, экономики, промышленности, инвестиционной и инновационной деятельности;

2) проведения экспертизы проектов законов Республики Татарстан, проектов иных нормативных правовых актов Республики Татарстан в сфере предпринимательства, экономики, промышленности, инвестиционной и инновационной деятельности (далее – проекты нормативных правовых актов);

3) участия в порядке, установленном нормативными правовыми актами Российской Федерации и Республики Татарстан, в проведении мониторинга законов Республики Татарстан и мониторинга правоприменения иных нормативных правовых актов Республики Татарстан в сфере предпринимательства, экономики, промышленности, инвестиционной и инновационной деятельности.

2. Органы государственной власти Республики Татарстан в пределах своей компетенции:

1) обеспечивают Палате доступ к информации о деятельности органов государственной власти Республики Татарстан в соответствии с Федеральным законом от 9 февраля 2009 года № 8-ФЗ «Об обеспечении доступа к информации о деятельности государственных органов и органов местного самоуправления», а также предоставляют информацию, необходимую для выполнения Палатой возложенных на нее функций и задач;

2) могут оказывать Палате экономическую поддержку в соответствии с законодательством Российской Федерации;

3) оказывают иное содействие в деятельности Палаты в формах, не противоречащих законодательству Российской Федерации и законодательству Республики Татарстан.

3. Представители Палаты в установленном порядке вправе присутствовать на заседаниях Государственного Совета Республики Татарстан и Кабинета Министров Республики Татарстан.

4. Представители Палаты по предложению органов государственной власти Республики Татарстан вправе участвовать в работе ведомственных, межведомственных и иных комиссий, экспертных советов, рабочих групп и других органов и организаций, образуемых указанными органами.

5. Представители Палаты в соответствии с нормативными правовыми актами органов исполнительной власти Республики Татарстан могут включаться в состав отраслевых коллегий и конкурсных комиссий, а также консультативных, экспертных и иных общественных советов, образуемых при органах исполнительной власти Республики Татарстан, при рассмотрении вопросов, связанных с предпринимательской деятельностью.

6. Органы государственной власти Республики Татарстан оказывают Палате содействие в выполнении ею своих уставных задач, принимают меры по обеспечению Палаты помещениями.

7. Вмешательство органов государственной власти Республики Татарстан и должностных лиц в деятельность Палаты, равно как и вмешательство Палаты в деятельность органов государственной власти Республики Татарстан и должностных лиц, не допускается.

Статья 5. **Взаимодействие Палаты с органами местного самоуправления**

Палата взаимодействует с органами местного самоуправления в порядке и формах, установленных Законом Российской Федерации «О торгово-промышленных палатах в Российской Федерации».

Статья 6. **Проведение Палатой экспертизы проектов нормативных правовых актов**

1. Проведение экспертизы проектов нормативных правовых актов осуществляется Палатой по предложению органа государственной власти Республики Татарстан либо по собственной инициативе.

2. Экспертиза проектов нормативных правовых актов проводится Палатой в срок, установленный соответствующим органом государственной власти Республики Татарстан.

3. Заключение Палаты по результатам экспертизы проекта нормативного правового акта должно содержать выводы о возможных социально-экономических последствиях принятия нормативного правового акта и

конкретные предложения по внесению изменений в проект нормативного правового акта в целях минимизации или предотвращения негативных последствий его принятия.

4. Заключение Палаты по результатам экспертизы проекта нормативного правового акта носит рекомендательный характер.

Статья 7. **Создание совместных консультативно-совещательных органов**

В целях координации деятельности по развитию предпринимательства, экономической и внешнеторговой деятельности органы государственной власти Республики Татарстан и Палата могут образовывать совместные консультативно-совещательные органы.

Статья 8. **Международные и межрегиональные связи Палаты**

1. Палата в соответствии со своим уставом может поддерживать прямые межрегиональные, международные контакты, заключать соответствующие соглашения с торгово-промышленными палатами субъектов Российской Федерации, зарубежных стран, иностранными организациями и предпринимателями, участвовать в осуществлении международных и внешнеэкономических связей Республики Татарстан.

2. Палата представляет интересы своих членов в международных организациях по вопросам, относящимся к ее компетенции.

3. Палата организует встречи и визиты делегаций российских и иностранных организаций и предпринимателей, симпозиумы, конгрессы, конференции и иные мероприятия по вопросам развития предпринимательства, экономической и внешнеэкономической деятельности.

4. Палата организует международные и межрегиональные выставки, ярмарки, а также обеспечивает подготовку и проведение выставок российских и республиканских товаров за рубежом.

Статья 9. **Вступление в силу настоящего Закона**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
13 ноября 2017 года
№ 81-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 26 октябрендә
кабул ителде

## 1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Россия Федерациясендә сәүдә-сәнәгать палаталары турында» 1993 елның 7 июлендәге 5340-1 номерлы Россия Федерациясе Законы (алга таба – «Россия Федерациясендә сәүдә-сәнәгать палаталары турында» Россия Федерациясе Законы) нигезендә Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы (алга таба – Палата) статусын, эшчәнлегенең, шулай ук Палатаның Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән үзара эшләү өлкәсендә аерым хокук мөнәсәбәтләрен билгели.

## 2 статья. **Палата статусы**

1. Палата берлек оештыру-хокукый рәвешендә төзелгән, ихтыярый нигездә Россия юридик затларын, шул исәптән юридик затларны һәм (яисә) индивидуаль эшкуарларны берләштерә торган Россия оешмаларын, шулай ук Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә теркәлгән индивидуаль эшкуарларны берләштерүче дәүләти булмаган коммерциягә карамаган оешма булып тора.

2. Палата үз эшчәнлеген «Россия Федерациясендә сәүдә-сәнәгать палаталары турында» Россия Федерациясе Законы, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, әлеге Закон, Татарстан Республикасының башка законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары, үз уставы нигезендә гамәлгә ашыра.

3. Палатаны төзү, шулай ук аның эшчәнлеген туктату принциплары һәм тәртибе «Россия Федерациясендә сәүдә-сәнәгать палаталары турында» Россия Федерациясе Законы белән билгеләнә.

4. Татарстан Республикасы территориясендә республика дәрәҗәсендә бары тик бер генә сәүдә-сәнәгать палатасы төзелә ала.

3 статья. **Палатаның максатлары һәм бурычлары**

1. Палата Татарстан Республикасы икътисадын һәм Россия Федерациясе икътисадын үстерүгә, заманча сәнәгать, финанс һәм сәүдә инфраструктурасын булдыруга, эшкуарлык эшчәнлегенә уңайлы шартлар тудыруга, эшкуарларның аларның социаль партнерлары белән мөнәсәбәтләрен җайга салуга, эшкуарлыкның барлык төрләрен, Татарстан Республикасында эшкуарларның Россия Федерациясенең башка субъектлары һәм чит илләр эшкуарлары белән сәүдә-икътисадый һәм фәнни-техник багланышларын һәрьяклап үстерүгә ярдәм итү максатларында төзелә.

2. Палата түбәндәге бурычларны башкара:

1) Татарстан Республикасында оешмаларга һәм индивидуаль эшкуарларга ярдәм күрсәтә, хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча аларның мәнфәгатьләрен белдерә һәм яклый, шул исәптән Татарстан Республикасыннан читтә һәм чит илләрдә;

2) Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең икътисадый мәнфәгатьләрен исәпкә алып эшкуарлык эшчәнлегенең барлык төрләрен, икътисад тармакларын, оешмаларны һәм индивидуаль эшкуарларны үстерүгә ярдәм күрсәтә;

3) Татарстан Республикасында эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының үзара эшләвен, аларның Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) һәм социаль партнерлар белән үзара эшләвен оештыра;

4) Татарстан Республикасында эшкуарлык эшчәнлеге өчен белем бирү һәм кадрлар әзерләү системасын үстерүгә ярдәм күрсәтә, шушы өлкәдә дәүләт һәм дәүләтара программалар эшләүдә һәм аларны гамәлгә ашыруда катнаша;

5) Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсеше фаразларын, Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсеше стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планын, эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль программаларны әзерләүдә катнаша;

6) Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеген, дәүләти-хосусый партнерлыкны, муниципаль-хосусый партнерлыкны үстерүгә ярдәм күрсәтә;

7) эшкуарларга, аларның берләшмәләренә, берлекләренә, ассоциацияләренә мәгълүмати хезмәт күрсәтә, эшкуарлыкка мәгълүмати хезмәт күрсәтү инфраструктурасын оештыруда ярдәм итә;

8) Татарстан Республикасы территориясендә җитештерелә торган товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр экспортын үстерүгә булышлык итә, Татарстан Республикасында оешмаларга һәм индивидуаль эшкуарларга тышкы базарда операцияләр үткәрүдә һәм сәүдә-икътисадый, фәнни-техник хезмәттәшлекнең яңа рәвешләрен үзләштерүдә гамәли ярдәм күрсәтә;

9) үзенә бирелгән хокуклар кысаларында намуссыз конкуренциягә һәм эшлекле булмаган партнерлыкка юл куймау һәм аларны кисәтү чаралары күрә;

10) Татарстан Республикасында эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары арасында килеп чыга торган бәхәсләрне җайга салуда ярдәм күрсәтә;

11) чит ил фирмаларының һәм оешмаларының коммерциячел эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итә;

12) «Россия Федерациясендә сәүдә-сәнәгать палаталары турында» Россия Федерациясе Законы нигезләмәләрен, Россия Федерациясе халыкара шартнамәләрен, Татарстан Республикасының тышкы икътисадый һәм регионара бәйләнешләрен гамәлгә ашыру турында килешүләрне исәпкә алып бүтән бурычларны башкара.

4 статья. **Палатаның Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән үзара эшләве**

1. Палата Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән үзара түбәндәге юллар белән эшли:

1) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына эшкуарлык, икътисад, сәнәгать, инвестиция һәм инновация эшчәнлеге өлкәсендәге Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларын камилләштерү тәкъдимнәре җибәрү;

2) эшкуарлык, икътисад, сәнәгать, инвестиция һәм инновация эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы законнары проектларына, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары проектларына (алга таба – норматив хокукый актлар проектлары) экспертиза үткәрү;

3) эшкуарлык, икътисад, сәнәгать, инвестиция һәм инновация эшчәнлеге өлкәсендәге Татарстан Республикасы законнары мониторингын һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларының хокук куллану мониторингын уздыруда Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә катнашу.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары үз компетенцияләре чикләрендә түбәндәгеләрне башкаралар:

1) Палатага «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итәләр, шулай ук Палата тарафыннан үзенә йөкләнгән функцияләрне һәм бурычларны үтәү өчен кирәкле мәгълүматны бирәләр;

2) Палатага Россия Федерациясе законнары нигезендә икътисадый ярдәм күрсәтә алалар;

3) Палата эшчәнлегенә Россия Федерациясе законнарына һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган рәвешләрдә башка ярдәм күрсәтәләр.

3. Палата вәкилләре билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышларында катнашырга хокуклы.

4. Палата вәкилләре Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тәкъдиме буенча алар тарафыннан төзелгән ведомство, ведомствоара һәм башка

комиссияләр, эксперт советлары, эшче төркемнәр һәм бүтән органнар, оешмалар эшендә катнашырга хокуклы.

5. Палата вәкилләре эшкуарлык эшчәнлегенә бәйле мәсьәләләрне караганда Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актлары нигезендә шушы органнар каршында төзелә торган тармак коллегияләре һәм конкурс комиссияләре, шулай ук консультатив, эксперт һәм башка иҗтимагый советлар составына кертелә алалар.

6. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары Палатага үз устав бурычларын үтәүдә ярдәм күрсәтә, аны биналар белән тәэмин итү чараларын күрә.

7. Палатаның Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм вазыйфаи затлар эшчәнлегенә кебек үк, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм вазыйфаи затларның Палата эшчәнлегенә тыкшынуы рөхсәт ителми.

5 статья. **Палатаның җирле үзидарә органнары белән үзара эшләве**

Палата җирле үзидарә органнары белән «Россия Федерациясендә сәүдә-сәнәгать палаталары турында» Россия Федерациясе Законында билгеләнгән тәртиптә һәм рәвешләрдә үзара эшли.

6 статья. **Палата тарафыннан норматив хокукый актлар проектларына экспертиза үткәрү**

1. Норматив хокукый актлар проектларына экспертиза Палата тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы тәкъдиме йә үз инициативасы буенча үткәрелә.

2. Норматив хокукый актлар проектларына экспертиза Палата тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең тиешле органы билгеләгән вакытта үткәрелә.

3. Норматив хокукый акт проектына экспертиза нәтиҗәләре буенча Палата бәяләмәсендә норматив хокукый актны кабул итүнең ихтимал булган социаль-икътисадый зыяннары турында нәтиҗәләр һәм аны кабул итүнең тискәре нәтиҗәләрен киметү яисә булдырмау максатларында норматив хокукый акт проектына үзгәрешләр кертү буенча конкрет тәкъдимнәр булырга тиеш.

4. Норматив хокукый акт проектына экспертиза нәтиҗәләре буенча Палата бәяләмәсе тәкъдим итү характерына ия була.

7 статья. **Уртак консультатив-киңәшмә органнар төзү**

Эшкуарлыкны, икътисадый һәм тышкы сәүдә эшчәнлеген үстерү эшен координацияләү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Палата уртак консультатив-киңәшмә органнар төзи алалар.

8 статья. **Палатаның халыкара һәм регионара багланышлары**

1. Палата үз уставы нигезендә турыдан-туры регионара, халыкара элемтәләр булдыра, Россия Федерациясе субъектлары, чит илләр сәүдә-сәнәгать палаталары, чит ил оешмалары һәм эшкуарлары белән тиешле килешүләр төзи, Татарстан Республикасының халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларын гамәлгә ашыруда катнаша ала.

2. Палата үз компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча халыкара оешмаларда үз әгъзаларының мәнфәгатьләрен белдерә.

3. Палата Россия һәм чит ил оешмалары, эшкуарлары очрашуларын һәм аларның делегацияләре визитларын, эшкуарлыкны, икътисадый һәм тышкы икътисадый эшчәнлекне үстерү мәсьәләләре буенча симпозиумнарны, конгрессларны, конференцияләрне һәм башка чараларны оештыра.

4. Палата халыкара һәм регионара күргәзмәләр, ярминкәләр оештыра, шулай ук чит илләрдә Россия һәм республика товарлары күргәзмәләре әзерләүне һәм үткәрүне тәэмин итә.

9 статья. **Әлеге Законның үз көченә керү тәртибе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2017 ел, 13 ноябрь
№ 81-ТРЗ